КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 декабрь г.Казань № 1075

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2024 ел, 20 сентябрь, 817 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2024 ел, 20 сентябрь, 817 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 26 декабрь, 1206 нчы; 2025 ел, 3 март, 123 нче; 2025 ел, 28 апрель, 273 нче; 2025 ел, 16 август, 613 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2025 елда күчмә сәүдәгә махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, ясалма яктырту технологиясен кулланып, ябык грунт яшелчәләре җитештерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган Вагон-хопперлар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктта «Татарстан Республикасында җитештерелгән ашлык» сүзләреннән соң «, авыл хуҗалыгы чималын эшкәртү барышында алынган продукция» сүзләрен өстәргә;

11 пунктның «в» пунктчасында «Татарстан Республикасында җитештерелгән ашлык» сүзләреннән соң «, авыл хуҗалыгы чималын эшкәртү барышында алынган

продукция» сүзләрен өстәргә;

14 пунктта «Татарстан Республикасында җитештерелгән ашлык» сүзләреннән соң «, авыл хуҗалыгы чималын эшкәртү барышында алынган продукция» сүзләрен өстәргә;

24 пунктта:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү елыннан соң килә торган елдан башлап 10 ел эчендә Татарстан Республикасында җитештерелгән ашлыкны, авыл хуҗалыгы чималын эшкәртү барышында алынган продукцияне вагоннар белән ташуны гамәлгә ашыру йөкләмәсе;»;

егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү елыннан соң килә торган елдан башлап 10 ел эчендә Татарстан Республикасында җитештерелгән ашлыкны, авыл хуҗалыгы чималын эшкәртү барышында алынган продукцияне вагоннар белән ташуны гамәлгә ашыру йөкләмәсе;»;

әлеге карар белән расланган Җитештерү куәтләрен модернизацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен икмәк пешерү предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 2 пунктындагы өченче абзацында «эшләнмәләр,» сүзеннән соң «һәм икмәк пешерә торган он җитештерү өчен,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга 2025 елда кучмә сәүдәгә махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, ясалма яктырту технологиясен кулланып, ябык грунт яшелчәләре җитештерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин